ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2021 г.Лениногорск № 618

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча 2021 елга торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләмен раслау турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1544 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында»2021 елның 28 июнендәге 506 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча 2021 елга торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләмен раслау турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1544 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 2 нче кушымтаны тәкъдим ителгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор – «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасары Г.А. Ивановага йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Н.С.Сосунова
5-19-26

Кушымт №2

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июнендәге 618 номерлы карарына

“Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә күп фатирлы йортларның торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен кертем күләме

| Түләү атамасы | Хезмәтнең үлчәү берәмлеге | хезмәт күрсәтү берәмлегенә тариф ( НДС белән сумнарда ) |
|---|---|---|
| Торак бина наймы | $м^2$ | 01.07.2021 дан 31.12.2021 га кадәр |
| | | 6,38 |